**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Урта Комар авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**10 ноябрь, 2021 ел** **№4**

**«Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 26 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Урта Комар авылы, Май урамы, 1Г йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2021 елның 26 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Урта Комар авылы, Май урамы, 1Г йорты адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, балачактан инвалид балалар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Урта Комар авылында материал сатып алу һәм чишмәне ремонтлау (килешү буенча түләү).
- Урта Комар авылында тирәннән суыртү насосы (глубинный насос) сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);
- Урта Комар авылында тышкы видеокүзәтү камераларын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча түләү).
- урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу (килешү буенча түләү).
- Урта Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Урта Комар авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Комар авыл җирлеге башлыгы: Ю.И. Исынбаев.